| | | |
|---|---|---|
| **ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.09.2013 № 7-19/т

Казан ш.

***Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» ААҖ тарафыннан пассажирлар йөртүгә чик дәрәҗә тарифлар билгеләү турында***

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 07 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» ААҖ тарафыннан пассажирлар ташуга тарифлар

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» ААҖ тарафыннан пассажирлар йөртүгә икътисадый нигезләнгән тариф дәрәҗәсен билгеләү турында» 2011 елның 1 апрелендәге 7-15/т номерлы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
20.09.2013 № 7-19/т
карарына кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» ААҖ тарафыннан пассажирлар ташуга чик дәрәҗәдә максималь тарифлар

| № п/п | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Иң чик максималь тариф (өстәмә хак салымы салынмый), сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1 | Алып бару аралыгына бәйсез рәвештә, сәфәр маршрутының беренче дистә чакрымыннан икенче дистә чакрымына кадәр бер пассажирны алып бару | 1 сәфәр | 18,00 |
| 2 | Пассажир юнәлгән юл буйлап, һәр зона өчен өстәмә рәвештә бер пассажирны өченче дистә километрдан башлап дүртенче дистә километрлы зонага алып бару | 1 зона | 12,00 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге